КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 10 октябрь г.Казань № 899

Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерүне, аларны саклау, кире кайтаруны оештыру, күчерү һәм саклау хакын түләү турында

«Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчерү һәм саклау хакын түләү тәртибе турында» 2012 елның 17 маендагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

«Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – учреждение) тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерүне, аларны саклауны һәм транспорт хуҗаларына, аларның вәкилләренә һәм шул транспорт чаралары белән идарә итү өчен кирәкле документлары булган затларга кире кайтаруны, транспорт чараларын тоткарлауны китергән административ хокук бозулар, тоткарланган транспорт чараларын күчерү һәм саклау хакын административ җаваплылыкка тартылган затларга Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексы нигезендә түләтүне оештыру буенча махсуслаштырылган учреждение булып тора;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына 30 көн эчендә тиешле үзгәрешләр кертергә:

оешма Уставына;

учреждениенең дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсенә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 30 көн эчендә әлеге карарның 1 пунктында каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле күчмә һәм күчемсез дәүләт мөлкәтен оператив идарә итү хокукында учреждениегә тапшырыга һәм беркетергә.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына 30 көн эчендә 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертергә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр тапшырырга.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә барлык оештыру чаралары тәмамланганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм алар карамагындагы учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын агымдагы тотуга норматив саны, пробегы һәм чыгымнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карарына әлеге карарга туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы карары проектын кертергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин